| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 25 апрель г.Казань № 523

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ведомствоара эшче төркем төзү турында» 2016 ел, 14 июль, 477 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ведомствоара эшче төркем төзү турында» 2016 ел, 14 июль, 477 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 19 апрель, 265 нче; 2019 ел, 13 июль, 580 нче; 2020 ел, 4 август, 648 нче; 2022 ел, 16 сентябрь, 1010 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Эшче төркем утырышлары кирәк булуга карап, әмма ярты елга кимендә бер тапкыр үткәрелә.»;

әлеге карар белән расланган гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем составында:

эшче төркем составыннан М.Н.Садыйковны, Г.Р.Шакированы чыгарырга;

эшче төркем составына Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры, эшче төркем рәисе урынбасары Марсель Мансур улы Миңнуллинны кертергә;

Светлана Хатыйп кызы Галиеваның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә караган сәламәтлек саклау мәсьәләләре секторы мөдире»;

Ирина Юрьевна Ермолаеваның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Фармация идарәсенә караган дару чаралары әйләнеше өлкәсендә җайга салу бүлеге башлыгы, эшче төркем секретаре»;

Елена Петровна Поляктованың вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе урынбасары (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин